**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлеге составына керүче Яңа Чәчкап торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре**

11 ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Яңа Чәчкап авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Яңа Чәчкап авылында коелар төзү, аларны ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (коеларны ремонтлау) өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2024 елның 11 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, халык җыенында катнашучылар исемлегенә 313 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны- 215 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 213 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлеге составына керүче Яңа Чәчкап авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Яңа Чәчкап авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Яңа Чечкап авылында коелар төзү, аларны ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (коеларны ремонтлау) өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Яңа Чәчкап авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Чәчкап авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: __________ Д.Д.Абдрахманова

Яңа Чәчкап авыл җирлеге башлыгы ____________________ Д.Д.Абдрахманова